**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**Яңа Аксубай авыл җирлеге составына керүче**
**Федоровский бистәсе гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

# КАРАР

2021 елның 15 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Яна Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яна Аксубай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 5 ноябрендәге 111 номерлы карары нигезендә, 2021 елның 15 ноябрендә Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегендә Федоровский бистәсе узган түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: «2022 елда Федоровский бистәсе җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торычыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, **500 сум** күләмендә үзара салым кертүегез һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

**1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
- вак таш сатып алу;
- Федоровский торак пункты чикләрендә юл полотносы урнаштыру, шул исәптән: грунт күтәрү, грейдирлау, вак таш салу, тигезләү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
-торак пункт эчендәге юлларны кышкы карап тоту, шул исәптән: грейдерлау, кардан чистарту, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү

«РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛДЫЛАР».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 67 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 37 граждан кертелгән.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 37 граждан тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.;

«ТЫЕЛДЫЛАР» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:
1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлеге составына керүче Федоровский торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре-чын мәгънәсендә.
2. "2022 елда һәр балигъ булган һәм Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Федоровский торак пунктының территориясендә теркәлгән кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә (1 төркем инвалид, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш) һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән алдагы эшләрне башкару буенча:

**1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- вак таш сатып алу;
- Федоровский торак пункты чикләрендә юл полотносы урнаштыру, шул исәптән: грунт күтәрү, грейдирлау, вак таш салу, тигезләү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- торак пункт эчендәге юлларны кышкы карап тоту, шул исәптән: грейдлау, кардан чистарту, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу.

3. Әлеге карарны Яңа Аксубай авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка җиткерергә һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы: А.В.Макаров